| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>ЭБАЛАКОВСКОГОСЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>ЯБАЛАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«23» декабрь 2020 ел Ябалак авылы № 15

«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләме нормативлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында»Ябалак авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 апрелендәге 66 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы сайланулы органнары әгъзаларының, муниципальберәмлекләрнең контроль-хисапорганнарырәисләренеңһәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1.«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләме нормативлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалак авыл җирлеге Советының 2018 елның 30 апрелендәге 66 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта:

3абзацта «11 163 сум» сүзләрен «11 498 сум» сүзләренә алмаштырырга;

1нче кушымтада«15300» саннарын «15759» саннарына алмаштырырга;

13нче кушымтаның 4 пунктынтүбәндәге эчтәлекле 4.1. пуктчасы белән тулыландырырга:

«4.1. Тиешле еллар эшләгән өчен пенсиягә чыгуга бәйле рәвештә бер мәртәбә акчалата ярдәм алу хокукына даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче һәмсалымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салым, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар,

процентлар түләү буенча  үтәлмәгән бурычы булмаган муниципаль хезмәткәрләр ия була.».

2. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Ябалакавыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең даими нигездә муниципаль вазыйфа биләүче затларга хезмәт өчен түләү күләме нормативлары, айлык һәм башка өстәмә түләүләр һәм аларны гамәлгә ашыру тәртибе турында» карарына үзгәрешләр кертү турында» Ябалакавыл җирлеге Советының  2020 елның 8 октябрендәге 9номерлы карарын юкка чыгарырга.

3.Әлеге карарны http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Кайбыч муниципаль районы Ябалакавыл җирлегенең рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

Татарстан Республикасы
Кайбыч муниципаль районы
Ябалак авыл җирлеге башлыгы  Гыйзәтуллина М. Ф.